**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге Советы**

**КАРАР № 17**

**Кече Урыссу ав.** **«11» сентябрь 2024 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге Советының 2024 елның
25 апрелендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы
8 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2024 елның 25 апрелендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 8 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:
«5) 1,2% карата:
- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар»

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә 1 ай узгач үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга., «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев